| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>«ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ПИСЬМЯНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ПИСМӘН<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** Подлесный **КАРАР**

2019 елның 11 марты №6

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проектын карау буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү турында хәбәр итү хакында

Муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышуда халыкның хокукларын, кешенең яшәү өчен уңай шартларына хокукларын, җир кишәрлекләре ияләренең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре хокукын саклау максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына таянып, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше Кодексының 5.1., 28нче статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җәмәгать тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 16.05.2012 ел, № 216 карары нигезендә әзерләнгән, составында: нигезләү материаллары (текст формасында), территориаль планлаштыру турында Нигезләмә, торак пунктларның чикләрен заманча куллану картасы, җирлекләрнең функциональ зоналары картасы, территориянең аерым шартлары булган зоналар чикләре картасы, җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру картасы, җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыруны планлаштыру картасы булган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Писмән авыл җирлеге» муниципаль

берәмлеге Генераль планы Проектын карау буенча ачык тыңлаулар үткәрү башлануы турында хәбәр итәргә.

2. 2018 елның 18 мартыннан 18 апреленә кадәр Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проектын карап тикшерү буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрергә.

3. 2019 елның 18 мартына кадәр Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проектын рәсми сайтта түбәндәге адрес буенча: http://Leninogorsk.tatar.ru «Шәһәр төзелеше» бүлегендә урнаштырырга.

4. 2019 елның 18 мартында Татарстан Республикасы, Лениногорск муниципаль районы, Подлесный поселогы, Гагарин урамы, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл җирлеге бинасында һәм Татарстан Республикасы, Лениногорск муниципаль районы, Иске Писмән авылы, Центральная урамы, 50 нче йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында Проект Эспозициясен ачарга.

Авыл җирлеге хакимияте бинасында проект экспозициясе белән танышу вакытын дүшәмбедән җомгага кадәр 9.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр һәм 14.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр итеп билгеләргә.

Экспозиция эше барышында «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына экспозициягә килүчеләргә консультация бирүне оештырырга.

5. Җәмәгать тыңлауларында катнашучыларга Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проектына кагылышлы тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен язмача Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Башлыгы исеменә ТР, Лениногорск районы, Гагарин урамы, 5 нче йорт адресы буенча тапшырырга, электрон рәвештә Pism.Len@tatar.ru адресына 2019 елның 18 мартыннан 18 апреленә кадәр, яки халык тыңлауларында катнашучылар җыелышын үткәрү барышында телдән формада җибәрергә тәкъдим итәргә.

6. Халык тыңлауларында катнашучылар җыелышы билгеләргә:
- 2019 елның 18 апрелендә 13.00 сәгатьтә, ТР, Лениногорск районы, Подлесный поселогы, Гагарин урамы, 1Б йорт, Подлесный поселогы МФЦ бинасында;
- 2019 елның 18 апреленә, 16.00 сәгатьтә, Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Писмән авылы, Центральная урамы, 50 нче йорт адресы буенча Иске Писмән авылы, Центральная, 50нче йорт, мәдәният йорты бинасында.

7. Җәмәгать тыңлаулары турында әлеге хәбәрне Лениногорск муниципаль

районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://Leninogorsk.tatar.ru., Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Подлесный поселогы, Гагарин урамы, 5 йорт, Подлесный бистәсе, Гагарин урамы, 1б йорт, Иске Писмән авылы, Центральная урамы, 50 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга, шулай ук «Лениногорские вести» газетасында бастырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Писмән авыл җирлеге»
муниципаль берәмлек башлыгы, Совет Рәисе Р. В. Насретдинов